**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**муниципального образования**
**«поселок городского типа**
**Актюбинский» Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Губкина, д. 24, п.г.т. Актюбинский,
Азнакаевский муниципальный район,
423304
тел. (факс): (85592) 3-16-63
E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**«Актүбә шәһәр тибындагы поселок»**
**муниципаль берәмлеге**
**БАШЛЫГЫ**

Губкин урамы, 24 йорт, Актүбә ш.т.п.,
Азнакай муниципаль районы, 423304
тел. (факс): (85592) 3-16-63
E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» октябрь 2025 ел № 4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль Законның 45 статьясы, 69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставның 14.1 статьясы нигезендә, карар бирәм:

1. 2025 елның 31 октябрендә 17 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендә, Актюбинская, Булатова, Нагорная, Пушкин, Садовая, Сайдашев, Строительная, Тукай, Х.Такташ урамнарында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

Үткәрү урыны: Актюбинская урамы, 41 адресы буенча урнашкан мәчет янында.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясе өлешендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез, 2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының

«Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, узара салым кертугә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең иске өлешендә урнашкан буаны чистарту):

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында веб-адрес: http://pravo.tatarstan.ru буенча һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес: http://aznakayevo.tatarstan.ru буенча, Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Актүбә ш.т.п., Губкин ур., 24 өй адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында 10 көн эчендә кабул ителгәннән соң урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык А.Л. Севостьянов